**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Тымытык авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Тымытык авылы № 89-158 «17» июнь 2025 ел

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларыныц һәм референдумда катнашу хокукыныц төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законныц 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл жирлеге Уставының 13 статьясы нигезендә,

Тымытык авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**:

1.Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Маяк " район газетасында кабул ителгән көненнән биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча http://aznakaevo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Э.Х.Гыйләҗева